ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21 февраль, 2018 ел № 23/8

Муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренен хезмәтенә түләү турында Шәһәр Советының аерым Карарларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 20 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 10 декабрендәге «Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеляренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 1072 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 703 санлы Карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 24 августындагы «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» № 678 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 735 санлы Карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 15 декабрендәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 18 октябрендәге «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 768 санлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 1000 санлы Карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 28 декабрендәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 14 августындагы 569 нчы карары белән расланган Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль учреждениеләр хезмәте өчен түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетлары чыгымнары күләмен билгеләү методикасына 2 нче кушымтага үзгәреш кертү хакында" 1064 Карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 29 декабрендәге»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хезмәт өчен түләүләре Бердәм тариф челтәре

нигезендә хисаплап чыгарыла торган Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслanучы оешмалар хезмәткәрләренә эш хакын арттыру турында» 2011 ел, 14 июнь, 477 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында", 1123 нче карарына нигезләнеп,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Хезмәт хаклары:

1) Шәһәр Советының 2015 елның 15 апрелендәге «Хезмәткә түләүнең яңа системасы кертелгән муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре өчен хезмәткә түләү шартларын билгеләү турында» 39/8 санлы Карары нигезендә (Шәһәр Советының 2016 елның 08 июлендәге 9/8, 2016 елның 15 декабрендәге 13/9, 2017 елның 29 мартындагы 16/6, 2017 елның 10 августындагы 18/5 санлы Карарлары редакциясендә)

2) Шәһәр Советының 2012 елның 20 декабрендәге «Шәһәр Советының 2010 елның 26 августындагы 53/7 санлы Карары белән расланган «Яр Чаллы шәһәренең аерым муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре өчен хезмәткә түләүнең яңа системасы турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында»22/8 санлы Карарының (Шәһәр Советының 2013 елның 21 февралендәге 23/6, 2013 елның 30 маендагы 25/7, 2013 елның 29 августындагы 26/5, 2014 елның 10 июлендәге 31/7, 2014 елның 09 декабрендәге 35/7, 2015 елның 15 апрелендәге 39/8, 2017 елның 29 мартындагы 16/6, 2017 елның 10 августындагы 18/5 санлы Карарлары редакциясендә) 6 пункты нигезендә

җайга салынган муниципаль учреждение хезмәткәрләренең вазифаи окладына, стимуллаштыру түләвенә (эш сыйфаты өчен түләүгә һәм премия түләвеннән тыш) 2018 елның 01 гыйнварыннан 14 процент күләмендә өстәмә түләү билгеләргә

2. Шәһәр Советының 2015 елның 15 апрелендәге 39/8 санлы Карары белән расланган муниципаль мәгариф оешмаларында һөнәри квалификация группасы вазыйфаларын башкаручы хезмәткәрләрнен хезмәтенә түләү шартлары турындагы Нигезнамәнең (Шәһәр Советының 2016 елның 08 июлендәге 9/8, 2016 елның 15 декабрендәге 13/9; 2017 елның 29 мартындагы 16/6, 2017 елның 10 августындагы 18/5 Каралары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 8 пунктның унтугызынчы абзацында «1,565» санын «1,675» санына алыштырырга;

2) 51 пунктның унынчы абзацын гамәлдән чыккан дип танырга.

3. Шәһәр Советының 2015 елның 15 апрелендәге 39/8 санлы Карары белән расланган муниципаль учреждениеләрнең физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификацион төркемнәре хезмәткәрләренә түләү шартлары турында Нигезнамәнең (Шәһәр Советының 2016 елның 08 июлендәге 9/8, 2017 елның 29 мартындагы 16/6 санлы Карарлары редакциясендә) 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$K_{m_j}$ – өстәмә белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт буенча укыту программаларын гамәлгә куючы физик культура һәм спорт буенча педагоглар өчен тармак приоритетын күтәрү коэффициенты 1,675, физик культура һәм спорт өлкәсендә профессиональ укыту программаларын гамәлгә куючы тренер - укытучылар өчен - 1,565;».

4. Шәһәр Советының 2012 елның 20 декабрендәге 22/8 санлы Карары белән расланган Муниципаль китапханәләр, музейлар һәм мәдәният-ял муниципаль мәдәният учреждениеләренең мәдәният хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификацион төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү шартлары турында Нигезнамәнең (Шәһәр Советының 2013 елның 21 февралендәге 23/6, 2013 елның 30 маендагы 25/7, 2013 елның 29 августындагы 26/5, 2014 елның 09 декабрендәге 31/7, 2017 елның 29 мартындагы 16/6 санлы Карарлары редакциясендә) 6 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) сигезенче абзацта «1,347» санын «1,441» санына алыштырырга;

2) тугызынчы абзацта «1,570» санын «1,680» санына алыштырырга;

3) унынчы абзацта «1,647» санын «1,762» санына алыштырырга;

4) уникенче абзацта «1,570» санын «1,680» санына алыштырырга.

5. Шәһәр Советының 2012 елның 20 декабрендәге 22/8 санлы Карары белән расланган башкару сәнгате муниципаль учреждениеләренең мәдәният хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификацион төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү шартлары турында Нигезнамәнең (Шәһәр Советының 2013 елның 21 февралендәге 23/6, 2013 елның 30 маендагы 25/7, 2013 елның 29 августындагы 26/5, 2014 елның 09 декабрендәге 31/7, 2017 елның 29 мартындагы 16/6 санлы Карарлары редакциясендә) 6 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) сигезенче абзацта «1,347» санын «1,441» санына алыштырырга;

2) тугызынчы абзацта «1,570» санын «1,680» санына алыштырырга;

3) унынчы абзацта «1,647» санын «1,762» санына алыштырырга;

4) уникенче абзацта «1,570» санын «1,680» санына алыштырырга.

6. Шәһәр Советының 2012 елның 20 декабрендәге 22/8 санлы Карары белән расланган муниципаль мәдәният учреждениеләренең фәнни тикшеренү һәм эшләнмәләр сферасындагы һөнәри квалификацион төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү шартлары турында Нигезнамәнең (Шәһәр Советының 2013 елның 21 февралендәге 23/6, 2013 елның 30 маендагы 25/7, 2013 елның 29 августындагы 26/5, 2014 елның 09 декабрендәге 31/7, 2017 елның 10 августындагы мартындагы 18/5 санлы Карарлары редакциясендә) 6 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) сигезенче абзацта «1,347» санын «1,441» санына алыштырырга;

2) тугызынчы абзацта «1,570» санын «1,680» санына алыштырырга;

3) унынчы абзацта «1,647» санын «1,762» санына алыштырырга;

4) уникенче абзацта «1,570» санын «1,680» санына алыштырырга.

7. Шәһәр Советының 2017 елның 20 июнендәге 17/5 санлы Карары белән расланган Хезмәтләренә түләү Бердәм тариф челтәре нигезендә башкарылган муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренә һәм хезмәткәрләренә түләү шартлары турында Нигезнамәнгә (шәһәр Советының 2017 елның 19 сентябрендәге 19/5 санлы Карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә :

«6. Бердәм тариф челтәренең учреждение хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү буенча тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлары):

| Бердәм тариф челтәренең түләү разрядлары | Тариф коэффициентлары | Тариф ставкалары (окладлары), сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | 1,0 | 2329,0 |
| 2 | 1,047 | 2438,0 |
| 3 | 1,09 | 2539,0 |
| 4 | 1,142 | 2660,0 |
| 5 | 1,268 | 2953,0 |
| 6 | 1,407 | 3277,0 |
| 7 | 1,546 | 3601,0 |
| 8 | 1,699 | 3957,0 |
| 9 | 1,866 | 4346,0 |
| 10 | 2,048 | 4770,0 |
| 11 | 2,241 | 5219,0 |
| 12 | 2,423 | 5643,0 |
| 13 | 2,617 | 6095,0 |
| 14 | 2,813 | 6551,0 |
| 15 | 3,035 | 7069,0 |
| 16 | 3,260 | 7593,0 |
| 17 | 3,511 | 8177,0 |
| 18 | 4,499 | 10478,0 |

Искәрмә: җитәкче урынбасарының тариф ставкасы (оклады) күләме тиешле җитәкченең тариф ставкасыннан (окладыннан) 1 - 2 разрядка түбәнрәк билгеләнә.»;

2) 11.1 пунктында:

– «7 210» санын «7 499» санына алыштырырга;

– «6 560» санын «6 823» санына алыштырырга.

8. Әлеге Карар рәсми басылганнан соң үз көченә керә.

1,7 пунктлар 2018 елнын 01 гыйнварыннан соң барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

2-6 пунктлар 2017 елнын 01 сентябреннән соң барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

9. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме                                        Н.Г. Мәһдиев